| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ГОРОДА МЕНЗЕЛИНСК<br>МЕНЗЕЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МИНЗӘЛӘ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>МИНЗӘЛӘ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.12.2023 г.Мензелинск № 3

«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 22 маендагы №1 Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Минзәлә шәһәре Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Кодекс» АИС ачыклаган туры килмәүләрне бетерү белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советы

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. “Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының “Минзәлә шәһәре” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында” 22.05.2020 № 1 Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Минзәлә шәһәре Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 статьяның 14 пунктында икенче җөмләне төшереп калдырырга.

1.2. 25 статьяның 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«7. Территориаль зоналар чикләре муниципаль берәмлекләр, торак пунктлар, җир кишәрлекләре чикләрен кисеп үтә алмый (Россия Федерациясе Җир кодексында яисә башка федераль законда каралган очракларда чикләре территориаль зоналар чикләрен кисеп үтә ала торган җир кишәрлегеннән тыш). Территорияләрдән, мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләреннән, федераль әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләре чикләреннән, Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләре чикләреннән файдалануның махсус шартлары булган территориаль зоналар чикләре белән кисешү рөхсәт ителә.».

1.3. 23 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле пункт өстәргә:
«- Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрындагы территориаль планлаштыру документларында күрсәтелгән торак пунктларның чикләренең урнашу урыны турында (шул исәптән торак пунктларның чикләрен җир кишәрлекләре чикләре белән кисешкән очракта) мәгълүматларның туры килмәве, ул күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына торак пунктлар чикләре турында

белешмәләр кертелгәндә федераль закон нигезендә үзгәртелгән күрсәтелгән торак пунктларның чикләре урынын тасвирлауга;»;

2.Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе А.Ф.Сәлахов